Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районыИске Михайловка авыл җирлегенең
Каськи авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы
КАРАРЫ

27 ноябрь 2021 ел №7

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2021елның 27ноябре 12 сәгать 00 минутта, узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә «Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Иске Михайловка авыл җирлегенең Каськи авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 5000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү максатыннан түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:территорияне төзекләндерү, сметалартөзү, техник күзәтү үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерүөчен түләү?»сорауларыбуенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 23 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 12 кеше, бу 52,1% тәшкилитә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 8-е«РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде;

гражданнар җыенында катнашучыларның4-е «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карарбирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегенең Каськи авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2.Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районыИске Михайловкаҗирлегенең Каськи авылында яшәү урыны буенча теркәлгән, даими яшәүче һәр кешедән үзара салым средстволарын 2022 елда 5000 сум күләмендә кертергә.

3. Җыелган үзара салым средстволарын җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерергә: территорияне төзекләндерү, сметалартөзү, техник күзәтү үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерүөчен түләү?».

4. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырырга, Иске Михайловка авылы, Школьная урамы, 43нче йорт, Ирекле авылы, Лесная урамы, 1а йорты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче И.М.Абдуллин